ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28 08 2025 г. № 1133

«Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында яшәмәгән, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр түләүсез туклandыруны оештыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 30 декабрендәге 956 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны социаль яклау максатларында һәм куллану бәяләре үсешен индексацияләүгә бәйле рәвештә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында (алга таба – карар) яшәмәгән, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр бушлай туклandыруны оештыру тәртибен раслау турында» 2022 елның 30 декабрендәге 956 номерлы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 2 нче кушымтасын кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкченең беренче урынбасары Р.М. Латыпов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
«28» 08 2025 № 1133

Кушымта № 2
Расланган
Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Башкарма комитеты
карары белән
№ 956 30 декабрь 2022 ел

Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында түбәндәге категориядәге балалар өчен туклану бәясе

| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1-4 нче сыйныфларында ике тапкыр туклану | | | | |
| Гомуми белем бирү оешмалары | Туклану бәясе, сум. | Муниципаль бюджет | Республика бюджеты | Федераль бюджет |
| Шәһәр, авыл һәм Кама Аланы штп | 136,02 | 61,25 | 31,40 | 43,37 |
| 5-11 нче сыйныфларда ике тапкыр туклану һәм бер тапкыр туклану | | | | |
| Гомуми белем бирү оешмалары | Туклану бәясе, сум. | Муниципаль бюджет | Республика бюджеты | Федераль бюджет |
| Шәһәр, авыл һәм Кама Аланы штп | 141,16 | 130,86 | 10,30 | - |